ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» июнь 2026 ел № 543

**“Арча үзәк район хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләүче яшь табибларга бер тапкыр бирелә торган матди түләү бирү турында**

“Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында” 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьясы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 23.1 статьясы нигезендә, яшь табибларга ярдәм итү һәм “Арча үзәк район хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең (алга таба – “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУ), Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУда эшләүче табибларга – яшь белгечләргә бер мәртәбә бирелә торган матди түләү турындагы нигезләмәне (1 нче кушымта) расларга.

2. “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУда эшләүче яшь табибларга бер тапкыр бирелә торган матди түләүне бүлү буенча комиссия төзергә һәм аның составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУда эшләүче табибларга – яшь белгечләргә бер тапкыр бирелә торган матди түләүне бүлү комиссиясе турында Нигезләмәне (3 нче кушымта) расларга.

4. “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУда эшләүче табибларга – яшь белгечләргә бер тапкыр бирелә торган матди түләү бирү турында килешү формасын расларга (4 нче кушымта).)

5. “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы” муниципаль казна учреждениесенә “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУда эшләүче табибларга – яшь белгечләргә Арча муниципаль районы бюджетының өстәмә чыганаклары исәбеннән бер тапкыр матди түләүне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүне йөкләргә.

6. Әлеге карарны “Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында” (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) урнаштырып халыкка чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча

муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Г.Шәймәрдановага йөкләргә.

Җитәкче Л. И. Абдуллин

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
“29 июнь 2026ел № 543
1нче кушымта

**“Арча үзәк район хастаханәсе”ДАССУда эшләүче табибларга – яшь белгечләргә бер тапкыр бирелә торган матди түләү турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУда эшләүче табибларга – яшь белгечләргә тиешле елда күрсәтелгән максатларга каралган Арча муниципаль районы бюджеты акчалары чикләрендә аларга ярдәм итү максатларында бер тапкры бирелә торган матди түләү тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Бер тапкыр бирелә торган матди түләү күләме һәр алучыга 200 000 (ике йөз мең) сум күләмендә билгеләнә. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бер тапкыр башкарыла.

3. Бер тапкыр бирелә торган матди түләүне “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУда эшләүче табиб – яшь белгечләр, шартлар җыелмасын үтәп, алуга дәгъва кылучылар булып тора:

- медицина юнәлеше буенча югары һөнәри уку йортын тәмамлаганнан соң “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУга эшкә урнашучылар (специалитет, интернатура, ординатура);

- “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУга 01.01.2026 елдан соңрак эшкә урнашучылар;

- түләүгә гариза биргән вакытка медицина эшчәнлегендә 3 елга кадәр стажы булган кешеләр;

- кимендә 1 ставкага эшләүчеләр;

- Татарстан Республикасының Арча муниципаль районында эшләүче яшь табибларга моңарчы бер тапкыр бирелә торган матди түләү алмаган табиблар;

- Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмаганнар.

4. Бер мәртәбә бирелә торган матди түләү алуга дәгъва кылучыларның гаризаларын карау эшен оештыру “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУда эшләүче табибларга – яшь белгечләргә бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне бүлү комиссиясенә (алга таба – комиссия) йөкләнә.

5. “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУда эшләүче яшь табибларга бер мәртәбә бирелә торган матди түләү алу өчен кандидатлар “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУның баш табибына гариза җибәрәләр, гариза алган көннән алып биш эш көне эчендә ул аларны “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУда эшләүче яшь табибларга бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне бүлү комиссиясенә җибәрергә тиеш.

6. “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУ комиссия каравына түбәндәге документларны җибәрә:

1) табиб – яшь белгечнең Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә бер мәртәбә бирелә торган матди түләү турында гаризасы;

2) бер мәртәбә бирелә торган матди түләү алуга дәгъва кылучының шәхесен

таныклаучы документның күчермәсе;

3) бер мәртәбә бирелә торган матди түләү алуга дәгъва кылучының белем алу турындагы дипломы күчермәсе;

4) бер мәртәбә бирелә торган матди түләү алуга дәгъва кылучының хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

5) эшкә алу турында боерык күчермәсе;

6) салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычның булмавы турында белешмә.

Документларның күчермәләре анда бер мәртәбә бирелә торган матди түләү алуга дәгъва кылучы эшли торган "Арча үзәк район хастаханәсе" ДАССУ җитәкчесе тарафыннан таныкланырга тиеш.

7. Документлар алынган вакыттан комиссия әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында каралган документларны 10 эш көне эчендә карый. Комиссиянең бер мәртәбә бирелә торган матди түләү бирү турындагы йә бирүдән баш тарту турындагы карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

8. Алучыга бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында каралган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау) ;

2) алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

3) Арча муниципаль районы бюджетында өстәмә чыганакларны финанс белән тәэмин итү булмаган очракларда.

9. Бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне алуга дәгъва кылучыларны сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат кандидатларга "Арча үзәк район хастаханәсе" ДАССУга комиссия утырышы беркетмәсен җибәрү юлы белән, табибларга – яшь белгечләргә бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне бүлү буенча комиссия утырышы уздырылган көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча җиткерелә.

10. Комиссия утырышы беркетмәсе комиссия утырышын үткәргән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрелә.

11. Комиссиянең барлык әгъзалары имзалаган беркетмәне алган көннән алып 15 эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты түләүне алучы һәм түләү күләме күрсәтелгән карар рәвешендә бирү турында карар кабул итә.

12. Бер мәртәбә бирелә торган матди түләү бирү өчен нигез булып Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты һәм бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне алучы арасында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә төзелгән килешү тора. Килешү карар имзаланганнан соң 20 эш көненнән дә соңга калмыйча төзелергә тиеш.

13. Акча күчерү бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне алучының банк счетына килешү төзелгәннән соң 60 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

14. Бер мәртәбә бирелә торган матди түләү алу турында төзелгән килешү нәтиҗәләре буенча, түләүне алучы "Арча үзәк район хастаханәсе" ДАССУда бер мәртәбә бирелә торган матди түләү алганнан соң кимендә 5 ел эшләргә тиеш.

15. Хезмәт килешүе 5 еллык срок тәмамланганчы туктатылган очракта, табиб – яшь белгеч хезмәт килешүе туктатылган көннән исәпләнгән бер тапкыр бирелә торган түләүнең бер өлешен эшләнмәгән чорга пропорциональ рәвештә хезмәт килешүе

туктатылган көннән алып 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджеты керемнә кайтара. Түләүне алучы инициативасы белән килешүне вакытыннан алда өзү өчен нигез булып тора:

- түләүне алучының үзе турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирүе;
- алучының әлеге Нигезләмәдә һәм төзелгән килешүдә каралган шартларны үтәмәве;
- эш бирүчегә түләү алучының хезмәт эшчәнлеге турында канәгатьләнерлек булмаган характеристикада булган фактлар документлар белән расланган объектив характеристика.

16. Нигезле сәбәп аркасында килешүнең гамәлдә булуы туктатылганда, түләүне алучының гомуми белем бирү оешмасында эшләп бетерүе килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору срогына озайтыла. Килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору өчен нигез булып тора:

- тиешле документлар (табиблар комиссиясе белешмәсе) белән расланган, эш бирүченең хезмәт эшчәнлегенә вакытлыча комачаулый торган түләү алучының озакка сузылган авыруы (ярты елдан артык вакытка);
- түләү алучының балаларының (якын туганнарының) эш бирүченең хезмәт эшчәнлегенә вакытлыча комачаулый торган, дәвалаучы табибның тиешле белешмәсе белән расланган озак вакытлы авыруы (ярты елдан артык срокка),;
- тиешле документлар белән расланган йөкле лек, бала табу, бала карау буенча отпусклар;
- түләүне алучыны Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына чакыру.

17. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктында каралган нигезләр барлыкка килгәндә эш бирүче 14 календарь көн эчендә комиссия секретарена килешүнең гамәлдә булуын өзү кирәклеге турында язма хәбәрнамәләр җибәрә, килешүне өзү нигезләрен раслый торган документлар да кушыла.

Килешүнең гамәлдә булуын өзү кирәклеге турында язма хәбәрнамәләр алган көннән алып 7 эш көненнән дә соңга калмыйча комиссия килешүнең гамәлдә булуын өзү турында Карар кабул итә, ул беркетмә белән рәсмиләштерелә. Комиссия утырышы беркетмәсе комиссия утырышын үткәргән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрелә.

18. Әлеге Нигезләмәнең 16 пунктында каралган нигезләр булганда, түләүне алучы нигезләр барлыкка килгән көннән алып 14 календарь көн эчендә комиссия секретарена килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору турында язма хәбәрнамәләр һәм килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору өчен нигезләрне раслый торган документлар җибәрә.

Килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору турында язма хәбәрнамәләр алынган көннән алып 7 эш көненнән дә соңга калмыйча комиссия беркетмә белән рәсмиләштерелә торган килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору турында карар кабул итә. Комиссия утырышы беркетмәсе комиссия утырышын үткәргән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
“29” июнь 2021ел № 543
2нче кушымта

**“Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУда эшләүче яшь табибларга бер тапкыр бирелә торган матди түләүне бүлү буенча комиссия**
**составы**

1. Абдуллин Ленар Илсур улы – Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе – комиссия рәисе.
2. Шәймәрданова Рәзилә Габделнур кызы – Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – рәис урынбасары
3. Низамиева Илмира Рамазан кызы – “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУның кадрлар хезмәте белгече комиссия секретаре (килешү буенча)
4. Ганиева Эльмира Нияз кызы – “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы” муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе – комиссия әгъзасы (килешү буенча).
5. Идирисов Рифат Ришат улы – “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУның баш табибы – комиссия әгъзасы (килешү буенча).
6. Понятова Амира Ивановна – халыкка медицина хезмәте күрсәтү буенча баш табиб урынбасары вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча).
7. Димитриева Марина Ивановна – Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының Бухгалтер исәбе һәм хисаплылык бүлеге җитәкчесе.
8. Фәйзрахманова Эльвира Минзәгыйть кызы – Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру-гомуми бүлеге җитәкчесе.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
“23 июнь 2026г” № 543
3нче кушымта

**“Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУда эшләүче табибларга – яшь белгечләргә бер тапкыр бирелә торган матди түләүне бүлү комиссиясе турында Нигезләмә**

1. “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУда эшләүче табибларга – яшь белгечләргә бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне бүлү комиссиясе (алга таба – комиссия) бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне бүлү турында объектив карар кабул итү максатыннан төзелде.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә әлеге Нигезләмәгә һәм “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУда эшләүче табибларга – яшь белгечләргә бер мәртәбә бирелә торган матди түләү турындагы нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Комиссиягә бер мәртәбә бирелә торган матди түләү алуда табибларның – яшь белгечләрнең документларын кабул итү һәм карау бурычлары йөкләнә.

4. Комиссия әгъзалары хокуклы:

1) комиссия утырышларын әзерләүдә катнашырга;

2) Комиссия рәисенә утырышны кичектереп тору турында тәкъдимнәр кертергә;

3 комиссия утырышында катнашырга;

4) комиссия тарафыннан карауга чыгарылган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашырга;

5) карауга чыгарылган мәсьәлә буенча фикерне бәян итәргә.

5. Комиссия рәисе комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук ул:

1 комиссия утырышларында рәислек итә һәм аның эшен оештыра;

2) комиссия утырышларында кабул ителгән карарларга имза сала.

6. Комиссия рәисе урынбасары комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук ул булмаганда комиссия рәисе вазыйфаларын башкара.

7. Комиссия секретаре комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) комиссиянең эш башкаруын алып бара;

2) материалларны комиссия утырышларына әзерләүне оештыра;

3) комиссия әгъзаларына комиссиянең чираттагы утырышын үткәрү урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында мәгълүмат бирә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;

4) комиссия утырышы беркетмәсен алып бара.

8. Комиссия утырышында аның составының кимендә өчтән икесе катнашса, комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала. Комиссия әгъзалары утырышта шәхсән катнашалар. Утырышта комиссия әгъзасы булмаган очракта, ул карала торган мәсьәлә буенча үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

9. Комиссия карарлары тапшырылган документларны карау һәм аларның түләү бирү Нигезләмәсе таләпләренә туры килү нәтиҗәләре буенча ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен комиссия әгъзаларының гомуми санынннан яртысыннан артыграгы тавыш биргән булса, кабул ителгән дип санала.

10. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

11. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
"29" июнь 2023ел ________ № 543
4нче кушымта

**"АРЧА ҮЗӘК РАЙОН ХАСТАХАНӘСЕ"ДАССУДА ЭШЛӘҮЧЕ ТАБИБЛАРГА - ЯШЬ БЕЛГЕЧЛӘРГӘ БЕР МӘРТӘБӘ БИРЕЛӘ ТОРГАН МАТДИ ТҮЛӘҮ БИРУ ТУРЫНДА КИЛЕШҮ ФОРМАСЫ**

Арча шәһәре "____" ____________ 20____ ел

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты, алга таба "Ззаказчы", Нигезләмә нигезендә эшләүче ________________________________ ___________________________Башкарма комитет җитәкчесе йөзендә, бер яктан, ______________________________________________________________________________________, алга таба "Табиб - яшь белгеч" дип атала, икенче яктан,
"Арча үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, алга таба "Эш бирүче" дип атала, "рча үзәк район хастаханәсе" ДАССУ баш табибы ______________ ___________________________________________ йөзендә, өченче яктан,
бергәяклар дип аталучылар түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр.

1. Килешү предметы

1.1. Эш бирүче тарафыннан "Арча район хастаханәсе" ДАССУда (алга таба – "Арча үзәк район хастаханәсе" ДАССУ) эшләүче яшь табибларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән тиешле елда күрсәтелгән максатларга каралган Арча муниципаль районы акчалары чикләрендә ярдәм күрсәтү килешүнең предметы булып тора.

2. Якларның йөкләмәләре

2.1. Заказчының Йөкләмәләре:
2.1.1. Заказ бирүче табиб – яшь белгечкә 200000 (ике йөз мең) сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган матди түләү түли.
2.2. Эш бирүченең йөкләмәләре:
2.2.1 "Арча үзәк район хастаханәсе"ДАССУда эшләүче табибларга - яшь белгечләргә бер тапкыр бирелә торган матди түләүне бүлү комиссиясенә беркетелгән документлар белән гаризалар кабул итәргә һәм билгеләнгән срокларда бер тапкыр бирелә торган матди түләүне бүлү комиссиясенә җибәрергә.
2.3. Табиб – яшь белгечнең йөкләмәләре:
2.3.1. Табиб – яшь белгеч үз ягыннан "Арча үзәк район хастаханәсе" ДАССУ белән төзелгән "____" _______________ 20_____ ел N _________ хезмәт шартнамәсе шартларын үтәргә, шушы килешү төзелгәннән соң 5 ел дәвамында _______________________________вазыйфада эшләргә, учреждениенең эчке тәртибе кагыйдәләрендә, вазыйфаи Инструкциядә билгеләнгән үз бурычларыңны намус белән үтәргә йөкләмә ала
2.3.2. Табиб-яшь белгеч хезмәт шартнамәсе үз инициативасы белән өзелгән очракта (тиешле документлар белән расланган медицина күрсәткечләре буенча шартнамәнең өзелү сәбәпләреннән тыш) аның гамәлдә булу срогы тәмамланганчы заказчыга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтүнең вакытына пропорциональ рәвештә күрсәтелгән сумманы учреждениедән эштән чыгару белән бер үк вакытта тулы күләмдә кайтарырга йөкләмә ала.

3. Килешүне үзгәртү һәм өзү

3.1. Килешү шартларын үзгәртү якларның килешүе буенча гына мөмкин.

3.2. Килешүне табиб - яшь белгеч инициативасы белән өзгәндә, бирелгән түләү суммасы законнар нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш. Түләүне алучы инициативасы белән килешүне вакытыннан алда өзү өчен нигез булып тора:

- табиб – яшь белгечнең үзе турында белә торып дөрес булмаган мәгълүматлар бирүе;
- табиб – яшь белгечнең "Арча үзәк район хастаханәсе" ДАССУда эшләүче һәм килешү төзегән яшь табибларга бер мәртәбә бирелә торган матди түләү турындагы нигезләмәдә каралган шартларны үтәмәве;
- табиб – яшь белгечнең хезмәт эшчәнлеге турында эш бирүчегә канәгатьләнерлек булмаган характеристикада булган фактлар документлар белән расланган объектив характеристика.

3.3. Нигезле сәбәпләр аркасында килешү гамәлдә булмау сәбәпле, табиб – яшь белгечнең "Арча үзәк район хастаханәсе" ДАССУда эшләве килешүнең гамәлдә булмау вакытына озайтыла. Килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору өчен нигез булып тора

- тиешле документлар (табиблар комиссиясе белешмәсе) белән расланган, эш бирүченең хезмәт эшчәнлегенә вакытлыча комачаулый торган түләү алучының озакка сузылган авыруы (ярты елдан артык вакытка);
- түләү алучының балаларының (якын туганнарының) эш бирүченең хезмәт эшчәнлегенә вакытлыча комачаулый торган, дәвалаучы табибның тиешле белешмәсе белән расланган озак вакытлы авыруы (ярты елдан артык срокка),;
- тиешле документлар белән расланган йөклелек, бала табу, бала карау буенча отпусклар;
- түләүне алучыны Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына чакыру.

4. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

4.1. Әлеге килешү аны имзалаган вакыттан алып яклар үз йөкләмәләрен тулысынча үтәгәнгә кадәр гамәлдә була.

5. Башка шартлар

5.1. Әлеге килешүдә каралмаган башка бөтен нәрсәдә яклар гамәлдәге законнарга таяналар.

5.2. Әлеге килешү буенча бәхәсләр законда билгеләнгән тәртиптә карала.

| Заказчы | Эш бирүче | Табиб – яшь белгеч |
|---|---|---|
| | | |